# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге составына керүче Көмеш-Күл торак пунктында 2021 елга үзара салым кертү турында

№ 5 19 ноябрь 2020 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлегенең Көмеш-Күл торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл авыл җирлеге Көмеш-Күл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 400( дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

**- ТР Мамадыш муниципаль районы Көмеш-Күл торак пунктында, Көмеш-Күл авыл җирлегендә яңа урам яктырткычлары сатып алу, ремонтлау һәм урнаштыру.**

**- Көмеш-Күл торак пунктында зират коймасын урнаштыру.**

**-ТР Мамадыш муниципаль районы Көмешкүл авыл җирлегенең Көмеш-Күл торак пунктында Үзәк урамын вакташ җәеп ремонтлау.**

**-Көмеш-Күл торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.**

3. Әлеге карарны Көмеш-Күл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Көмеш-Күл авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе И.Н.Сәләхетдинов.